**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№960**
**15.02.2023**

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә
шәһәр конкурсы үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы карары белән расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү программасын үтәү йөзеннән, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче әдәбият һәм сәнгать өлкәсе хезмәткәрләренең иҗади активлыгын күтәрү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә 2023 елның март-апрелендә Яр Чаллы шәһәрендә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шәһәр конкурсы үткәрергә.

2. Расларга:

1) әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шәһәр конкурсын үткәрү чыгымнарын финанслауны 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Мәдәният» 0801 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 230 000,00 (ике йөз утыз мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 15 февралендәге
960 номерлы карарына
1 нче кушымта

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурска аеруча талантлы, яңалыгы, үзенчәлеге, югары сәнгать дәрәҗәсе ягыннан аерылып торучы, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә иң югары казанышларга ирешүгә, аларны саклауга һәм җәелдерүгә булышлык итүче әдәбият һәм сәнгать әсәрләре чыгарыла.

3. Конкурс «Әдәбият», «Сынлы сәнгать», «Музыка һәм башкару сәнгате», «Театр сәнгате» номинацияләре буенча үткәрелә.

4. Конкурсның оештыручысы булып Башкарма комитетының мәдәният идарәсе тора.

2 бүлек. Конкурсның максаты һәм бурычлары

5. Конкурс Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең иҗади активлыгын күтәрү максатында үткәрелә.

6. Конкурсның бурычлары**:**

1) мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләренең иҗатын активлаштыру;

2) конкурста катнашучыларга мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә автор идеяләрен һәм уңышларын демонстрацияләү өчен мөмкинлек бирү;

3) конкурста катнашучыларны югары сәнгать әсәрләре иҗат итүгә рухландыру һәм булышлык итү.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

7. Конкурста үз эшчәнлекләрен мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә гамәлгә ашыручы мәдәният учреждениеләре, дәүләтнеке булмаган һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр), коммерциясез оешмалар, иҗат коллективлары һәм физик затлар катнашырга мөмкин.

8. Конкурска түбәндәге әсәрләр тәкъдим ителергә мөмкин:

1) әдәбият һәм әдәбият белеме өлкәсендә – матбугатта басылганнан соң;

2) музыка, театр, хореография, эстрада, сынлы сәнгать өлкәсендә – аларны концертларда, күргәзмәләрдә, театрларда, радио һәм телевидение аша халыкка җиткергәннән һәм алар белән җәмәгатьчелекне таныштырганнан соң.

9. Конкурска 2020-2022 елларда басылып чыккан (башкарылган, күрсәтелгән, ясалган) әсәрләр кабул ителә.

10. Башкарма комитетның мәдәният идарәсе конкурс игълан итү турындагы хәбәрне массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрә.

11. Конкурста катнашучылар 2023 елның 28 мартына кадәр документларны кәгазь һәм электрон йөрткечтә Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә тапшыралар (354 кабинет), т. 30-58-81.

12. Конкурс документлары түбәндәге материалларны үз эченә алырга тиеш:

1) әлеге нигезләмәгә 1 нче, 2 нче, 3 нче кушымталарда каралган форма буенча гариза;

2) «Әдәбият» номинациясендә – автор (авторлар) турында кыскача мәгълүмат, басылып чыккан әдәби әсәр;

3) «Сынлы сәнгать», «Музыка һәм башкару сәнгате», «Театр сәнгате» номинацияләрендә – фото, видео яки аудиоязма, әсәрнең төренә һәм жанрына карап, сынлы сәнгать, скульптура, графика әсәрләренең, нота җыентыкларының, тавыш һәм видеоязмаларның, фотосурәтләрнең төп нөсхәләре һәм күчермәләре;

4) конкурска тәкъдим ителгән әсәрләргә карата фикерләр яисә рецензияләр теркәү мәҗбүри.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

13. Конкурс җиңүчеләрен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) билгели. Комиссия, ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш нигезендә, әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән номинацияләр буенча конкурс җиңүчеләрен билгели. Комиссия карары конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Конкурска йомгак ясау – 2023 елның 12 апреленә кадәр.

14. Комиссия әсәрләрне түбәндәге критерийлар буенча бәяли:

1) югары профессиональ дәрәҗә;

2) яңалык һәм үзенчәлек (уникальлек, кабатланмас булу);

3) авторның стиль үзенчәлеге;

4) гражданлык үзаңын актуальләштерү;

5) гуманлылык, гаделлек, әхлаклылык, игелеклелек идеяләрен пропагандалау;

6) Яр Чаллы шәһәренә, анда яшәүче кешеләргә, аның тарихына һәм мәдәниятенә карата кызыксыну уяту.

15. Комиссия билгеләнгән срокта тапшырылган материалларны карый, аларның тулылыгын, дөреслеген тикшерә. Материалларны тапшыру срокларын бозу конкурста катнашуга гаризаны кире кагу өчен нигез булып тора.

16. Конкурс нәтиҗәләре буенча һәр номинациядә бер җиңүче билгеләнә. Комиссия номинацияләрдә җиңүчене билгеләмәү хокукына ия.

17. «Әдәбият» номинациясендә җиңүче 57 500,00 сум (илле җиде мең биш йөз сум 00 тиен) күләмендә акчалата приз белән бүләкләнә.

18. «Сынлы сәнгать» номинациясендә җиңүче 57 500,00 сум (илле җиде мең биш йөз сум 00 тиен) күләмендә акчалата приз белән бүләкләнә.

19. «Театр сәнгате» номинациясендә җиңүче 57 500,00 сум (илле җиде мең биш йөз сум 00 тиен) күләмендә акчалата приз белән бүләкләнә.

20. «Музыка һәм башкару сәнгате» номинациясендә җиңүче 57 500,00 сум (илле җиде мең биш йөз сум 00 тиен) күләмендә акчалата приз белән бүләкләнә.

21. Акчалата приз авторлар коллективына бирелгән очракта, ул авторлар коллективының барлык әгъзалары арасында тигез өлешкә бүленә.

22. Конкурста җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнә. Бүләкләү Габдулла Тукай скверында тантаналы чарада башкарыла.

23. Акчалата призны түләү акчаларны конкурста җиңүченең шәхси счетына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Әдәбият һәм сәнгать
өлкәсендә шәһәр конкурсы
үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Мәдәният учреждениеләре өчен
әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге шәһәр конкурсында катнашуга гариза
формасы

1. Номинациянең исеме
2. Проектның исеме
3. Проект җитәкчесе турында мәгълүмат
   Ф.И.А.и.
   Вазыйфасы
   Паспорт мәгълүматлары
   (серия) (номер)
   (кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
   Яшәү урыны буенча теркәлгән фактик адресы
   Элемтә телефоны
   Электрон почта
4. Гариза бирүче оешманың исеме
5. Гариза бирүче оешма җитәкчесенең Ф.И.А.и. һәм вазыйфасы
6. Оешманың адресы
7. Юридик
8. Фактик
9. Оешманың тел./факсы
10. Электрон почта
11. Оешманың реквизитлары
    Банкның исеме
    Исәп-хисап счеты №
    ИНН
    БИК
    ОКОНХ
    ОКПО
12. Проект буенча хисаплылык әзерләү өчен җаваплы бухгалтерның Ф.И.А.и.
13. Гариза бирү датасы

Әдәбият һәм сәнгать
өлкәсендә шәһәр конкурсы
үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Физик затлар өчен әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге
шәһәр конкурсында катнашуга гариза
формасы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Проектның авторы – Ф.И.А.и. | ______________________ |
| 2. | Гариза бирүченең адресы | ______________________ |
| 3. | Эш урыны | ______________________ |
| 4. | Вазыйфасы | ______________________ |
| 5. | Паспорт мәгълүматлары | ______________________<br>(серия) (номер)<br>______________________<br>(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән) |
| 6. | Яшәү урыны буенча теркәлгән фактик адресы | ______________________ |
| 7. | Элемтә телефоны | ______________________ |
| 8. | Электрон почта | ______________________ |
| 9. | Номинациянең исеме | ______________________ |
| 10. | Гариза бирү датасы | ______________________ |

Әдәбият һәм сәнгать
өлкәсендә шәһәр конкурсы
үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Дәүләтнеке булмаган һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр), коммерциясез оешмалар, иҗат коллективлары өчен әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге шәһәр конкурсында катнашуга гариза формасы

1. Номинациянең исеме ____________________
2. Оешма (берләшмә) турында мәгълүматлар ____________________
3. Гариза бирүченең – оешма (берләшмә) җитәкчесенең Ф.И.А.и. ____________________
4. Паспорт мәгълүматлары ____________________
   (серия) (номер)
   ____________________
   (кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
5. Оешманың (берләшмәнең) фактик адресы ____________________
6. Оешманың (берләшмәнең) юридик адресы ____________________
7. Оешманың (берләшмәнең) электрон почтасы ____________________
8. Оешманың (берләшмәнең) элемтә телефоны ____________________
9. Оешманың (берләшмәнең) тел./факс ____________________
10. Оешманың (берләшмәнең) реквизитлары ____________________
    Банкның исеме ____________________
    Исәп-хисап счеты № ____________________
    ИНН ____________________
    БИК ____________________
    ОКОНХ ____________________
    ОКПО ____________________
11. Проект буенча хисаплылык әзерләү өчен җаваплы бухгалтерның Ф.И.А.и. ____________________
12. Гариза бирү датасы ____________________